ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) 3 пунктта «башкарма хакимиятнең федераль мөлкәтне хосусыйлаштыруны гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль органына» сүзләрен «федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру функцияләрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) ел саен, 1 марттан да соңга калмыйча, дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнары (программалары) үтәлеше йомгаклары турындагы хисапларның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган рәвешләре нигезендә узган елда дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәләре хакындагы мәгълүматны, шулай ук муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру функцияләрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимият органына тапшыра;»;

2) 6 статьяның 2 өлешендә «унитар предприятиеләрнең мөлкәт комплекслары» сүзләрен «унитар предприятиеләр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 11 декабрь
№ 84-ТРЗ